Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге Советының утыз сигезенче утырышы

Күн авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

25 октябрь, 2024 ел № 103

«Җир салымы турында» 2023 елның 11 сентябрендәге 74 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге нигезендә Питрәч муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. «Җир салымы турында» 2023 елның 11 сентябрендәге 74 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктта:

а) 2 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«(2) торак-коммуналь комплексның торак фонды һәм (яисә) инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегеннән тыш) торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамый торган яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) салым базасының 0,3 %ы, эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш;»;

б) 4 пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«(4) шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата салым базасыннан 0,3 %, моңа һәрберсенең кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләре керми;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы
Күн авыл җирлеге башлыгы Р.Г. Баһауов